ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

«20» февраль 2023 ел № 21-р

Әгерҗе муниципаль районында шәхси ярдәмче хуҗалыкта сөт юнәлешендәге кече-фермалар төзелешен даими тикшерү комиссиясен төзү турында

"Татарстан Республикасы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәме чаралары турында" 15.06.2021 елның 452 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы бюджетыннан шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга сөт юнәлешендәге кече-фермалар төзүгә чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр бирүгә бәйле рәвештә сыерларны тотуның ветеринария кагыйдәләре таләпләрен үтәүне тикшерү, шәхси ярдәмче хуҗалыкта төзелгән яки төзелә торган кече-фермаларның булу-булмавын һәм факттагы торышын актлаштыру максатларында:

1. Әгерҗе муниципаль районында шәхси ярдәмче хуҗалыкта кече-фермалар төзелешен тикшерү буенча даими комиссия төзергә һәм аның составын расларга (кушып бирелә).

2. Оештырылган комиссия шәхси ярдәмче хуҗалыкларда сыерларны тотуның ветеринария кагыйдәләрен, Әгерҗе муниципаль районының шәхси ярдәмче хуҗалыкларында төзелгән яки кече-фермалар төзү стадиясендә булган торышын үтәп, сөт юнәлешендәге кече-фермаларны төзү мөмкинлеге турында бәяләмә үткәрергә, тиешле бәяләмә әзерләргә һәм аны Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек кечестрлыгына юлларга.

3. Әлеге күрсәтмәне “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә. Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://agryz.tatarstan.ru)

4. Әлеге күрсәтмәнең үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары К. М. Сотовка йөкләргә.

**Җитәкчесе** **Л.Ф. Нургаянов**

Татарстан Республикасы Әгерже
муниципаль районы Башкарма
комитетының 20.02.2023 № 21-р
күрсәтмәсе белән расланды

Әгерже муниципаль районында шәхси ярдәмче хуҗалыкта сөт юнәлешендәге кече-фермалар төзелешен даими тикшерү комиссиясе составы

1. Сотов Константин Михайлович – Әгерже муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, комиссия рәисе;
2. Хазиева Лилия Ринатовна - Әгерже муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгы, комиссия әгъзасы;
3. Заитова Аида Салиховна - Әгерже муниципаль районы Башкарма комитетының Икътисадый үсеш бүлеге башлыгы, комиссия әгъзасы;
4. Гатауллин Дилүс Гаскәрович - Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек кечестрлыгының Әгерже муниципаль районында авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы, комиссия әгъзасы (килешү буенча);
5. Закиров Ренат Рафаэлевич - "Әгерже район дәүләт ветеринария берләшмәсе" ДБУ башлыгы, комиссия әгъзасы (килешү буенча)